**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШИЛЬНЕБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«15» августа 2019 ел №29

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 15 өлеше 13 маддәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 октябрендәге 880 санлы карары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлеге уставы нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен расларга (алга таба – тәртип).

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Шильнебаш авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе О.А. Гончарова